СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**12.10.2017**

.Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 244**

Зеленодольск муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегеннән Татарстан Республикасы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль милкенә тапшыру өчен тәкъдим ителә торган муниципаль мөлкәт исемлеген раслау турында» 2010 елның 23 апрелендәге 519 номерлы карары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкенә кабул итү-тапшыру акты буенча милекне Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкенә тапшыру фактта башкарылмаганга күрә, Зеленодольск муниципаль район Советының 2010 елның 23 апрелендәге 519 номерлы карары нигезендә, Россия Федерациясе Граждан кодексы, 2007 елның 28 мартында Зеленодольск муниципаль район Советының 162 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, Зеленодольск муниципаль район Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегеннән Татарстан Республикасы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль милкенә тапшыру өчен тәкъдим ителә торган муниципаль мөлкәт исемлеген раслау турында» 2010 елның 23 апрелендәге 519 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск**
**муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А.В. Тыгин**